ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.07.2021 Казан шәһәре № 84-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе ведомство бүләген гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе, шулай ук Татарстан Республикасы ветеринария оешмалары хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте үсешенә актив ярдәм күрсәткән затларны бүләкләү системасын камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе ведомство бүләген гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе турында нигезләмә.

2.2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесенә тасвирлама.

2.3. Әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесенең эскизын.

2.4. Әлеге боерыкка 4 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим итү формасын.

3. Бүләкләү өчен материаллар әзерләү, ведомство бүләген исәпкә алу һәм бирү эшен оештыруны, шулай ук бүләкләү документларын рәсмиләштерүгә методик җитәкчелек итүне кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә йөкләргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.Н.Ногуманов

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2021 елның 29 июлендәге № 84-од боерыгына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе турында нигезләмә

1. «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе (алга таба – Күкрәк билгесе) белән ветеринария өлкәсендә кимендә 5 ел эшләгән затлар бүләкләнә:

күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте бурычларын хәл итүдәге казанышлары өчен;

Ветеринария идарәсе эшчәнлегенә бәйле норматив хокукый актларны эшләүгә керткән өлеше өчен;

авыл хуҗалыгы, йорт, зоопарк һәм башка хайваннарны да кертеп, хайваннарның, кошларның, балыкларның, бал кортларының йогышлы һәм башка төрле авыруларын бетергәндә күрсәткән, инициатив гамәлләре өчен;

ветеринария иминлеген үстерү һәм ныгытудагы казанышлары өчен;

ветеринария өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда актив катнашканы өчен;

ветеринария өлкәсендә фән казанышларын һәм алдынгы тәҗрибәне гамәлгә керткән өчен;

эпизоотиягә каршы чаралар оештыру һәм уздыру, авыл хуҗалыгы хайваннарының массакүләм йогышлы булмаган авыруларын профилактикалауга бәйле эше өчен.

2. Күкрәк билгесе белән бүләкләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең (алга таба – Ветеринария идарәсе) Мактау грамотасы белән бүләкләнгәннән соң кимендә 2 ел узгач гамәлгә ашырыла.

3. Күкрәк билгесе белән бүләкләү Ветеринария идарәсе боерыгы нигезендә Ветеринария идарәсе җитәкчесе урынбасарлары, Ветеринария идарәсенең структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм ведомствога буйсына торган оешмаларның җитәкчеләре үтенече буенча башкарыла.

4. Күкрәк билгесе белән бүләкләү турындагы үтенеч Ветеринария идарәсе җитәкчесе исеменә тапшырыла.

5. Күкрәк билгесе белән бүләкләү турындагы үтенечкә әлеге Боерыкның 4 нче кушымтасы нигезендә Күкрәк билгесе белән бүләкләүгә күрсәтмә теркәлә.

6. Бүләккә тәкъдим ителү вакытыннан алда килгән бер календарь елы дәвамында алынмаган (түләнмәгән) дисциплинар бурычлары булган затлар Күкрәк билгесе белән бүләкләнә алмый.

7. Күкрәк билгесе Ветеринария идарәсе коллегиясе утырышларында яисә Ветеринария идарәсе эшчәнлегенә багышланган тантаналы чараларда (һөнәри бәйрәмнәрдә, юбилей даталарында) тапшырыла.

8. Күкрәк билгесен Ветеринария идарәсе җитәкчесе тапшыра. Аерым очракларда ветеринария идарәсе җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә һәм аның исеменнән Күкрәк билгесен аның урынбасарлары тапшыра.

9. Күкрәк билгесе күкрәкнең уң ягында йөри һәм дәүләт бүләкләреннән астарак урнаштырыла.

10. Күкрәк билгесе белән кабат бүләкләү гамәлгә ашырылмый.

11. Югалганы урынына алмаш итеп Күкрәк билгесенең дубликаты бирелми.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2021 елның 29 июлендәге № 84-од боерыгына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы»
күкрәк билгесенә тасвирлама


«Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе 750 пробалы алтын йөгертелгән җиздән эшләнгән һәм 32 мм диаметрлы түгәрәк формасында, ә медальнең аркылы кисеме шомартып ялтыратылган. Түгәрәк фонында елан белән Асклепий таягы һәм аның астында латинча «V» хәрефе сурәтләнгән. Түгәрәк «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» дигән язулы боҗра эчендә урнашкан. «Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» дигән язу хәрефләренең үлчәме – 2 мм. Күкрәк билгесе элмәк белән боҗра ярдәмендә яшел-ак-кызыл төсендәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсендәге) турыпочмаклы кысага тоташа. Кысаның икенче ягында билгене киемгә тагу өчен эләктергеч бар.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2021 елның 29 июлендәге № 84-од боерыгына 3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесенең эскизы




Аверс



Реверс

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2021 елның 29 июлендәге № 84-од боерыгына 4 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы ветеринария хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим итү

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________________________________
2. Вазыйфасы, эш, хезмәт урыны ______________________________________________________
______________________________________________________________________________
(Ветеринария идарәсендәге структур бүлекчәнең, башка оешманың тулы исемен күрсәтергә)
3. Туу датасы ______________________________________________________________________
4. Белеме _________________________________________________________________________
5. Тәмамлаган ______________________________________________________________________
(белем йортының атамасы, тәмамлау елы)
6. Белеме буенча белгечлеге __________________________________________________________
7. Нинди дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән, дата
______________________________________________________________________________
8. Гомуми эш стажы ______________ Тармактагы эш стажы _______________
Әлеге коллективта эш стажы ________________
9. Бүләккә тәкъдим ителгән затка, конкрет аерым, әһәмиятле шәхси казанышларын күрсәтеп, характеристика: ______________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

10. ________________________________________ ___________ ____________________________
(тәкъдим керткән затның вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе һәм инициаллары)

«___» ____________ 20___ ел